**Тукай муниципаль районы**
**Түбән Суык-Су авыл җирлеге**
**Түбән Суык-Су авылы**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

27 октябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Балалар мәйданчыгы өчен балалар уены элементларын сатып алу.
- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү.
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементларын сатып алу.
- Су челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре).
- Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту).
- Күлне камышлардан чистарту.
- Янгын инвентарен сатып алу һәм урнаштыру (гидрант, көпшә, җиңсә).
- Күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү.
- Ташуга каршы чаралар (траншеялар урнаштыру, туфрак өеме).
- Агачлар кисү

2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Түбән Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов